СОВЕТ МАЛОКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.З.Закирова, д.47, с. Малые Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422172

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИРМӘНАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
З.Закиров ур., 47 нче йорт, Кече Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422172

тел.(факс): (85563) 2-96-17; e-mail: MKir.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
№ 1-26

Решение
02 нче октябрь 2017 ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кече Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Кече Кирмән авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 че сентябрендә кабул ителгән 14 нче номерлы карары, Кече Кирмән авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 нче сентябрендә кабул ителгән 2-24 нче номерлы карары, Кече Кирмән авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кече Кирмән авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре”, 2014 нче елның 2 нче апрелендә кабул ителгән 2-33 нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2017 нче елның 19 нче ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби

хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия  Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел пожар куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын булдыру :

Пожар гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру:

- Кече Кирмән торак пунктында, Норма торак пунктында, Югары Яке торак пунктында, Норма урман хуҗалыгы торак пунктында, Су-Елга торак пунктында.

2. Авыл жирлеге торак пунктларында су белән тәэмин итү:

Кече Кирмән торак пунктында су алу башнясы урнаштыру

Кече Кирмән торак пунктында, Норма торак пунктында, Югары Яке торак пунктында, Норма урман хуҗалыгы торак пунктында су башняларын техник яктан җиһазландыру өчен җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, территорияне әйлэндереп алу

« ӘЙЕ » « ЮК »

4. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы Г.М.Аскаровка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе /Г.М.Аскаров/